**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итү**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең генераль планы проекты (алга таба-проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

Проектның мәгълүмати материаллары:

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;
- торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре)картасы;
- функциональ зоналар картасы;
- җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре турында белешмәләр, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге;
- Генераль планны нигезләү буенча материаллар.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

Проект буенча ачык тыңлаулар 2026 елның 6 февраленнән 2026 елның 20 февраленә кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;

- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Проект буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең бөтен территориясендә (алга таба – Кощаково авыл җирлеге) Кощаково авылы, Званка авылы, Иске Кощаково авылы һәм Царево авылы торак пунктлары өлешендә үткәрелә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре,
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Царево авылы халкы өчен: 2026 елның 17 февралендә 10 сәгать 00 минутта Лесная урамы башында (422772, РТ, Питрәч районы, Царево авылы, Лесная урамы);

- Званка авылы халкы өчен: 2026 елның 17 февралендә 11 сәгать 00 минутта Званка МФЦ фойесында (422772, РТ, Питрәч районы, Званка авылы, Яшьлек ур., 4 й.);

- Иске Кощаково авылы халкы өчен: 2026 елның 17 февралендә 13 сәгать 00 минутта кибет янында (422772, РТ, Питрәч районы, Иске Кощаково авылы, Луговая ур., 65 й.);

- Кощаково авылы халкы өчен: 2026 елның 17 февралендә 14 сәгать 00 минутта Кощаково мәдәният йортының тамаша залында (422772, РТ, Питрәч районы, Кощаково авылы, Центральная ур., 19 й.).

Проект экспозициясен оештыру:

- 2026 елның 16 февралендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге веб буенча рәсми сайтында - түбәндәге адрес буенча: https://pestreci.tatarstan.ru/generalniy-plan-598960.htm «Проектлар экспозициясе» вкладкасында, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авылы, Комсомольская урамы, 13 йорт;

Интернет челтәрендә веб - адрес буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылган проект материаллары белән: https://pestreci.tatarstan.ru/generalniy-plan-598960.htm экспозициянең бөтен срогы дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. 2026 елның 16 февралендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проект белән 09.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) танышырга була.

2026 елның 16 февраленнән 2026 елның 17 февраленә кадәр гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручы адресына, адресы буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авыл җирлеге, Комсомол ур., 13 йорт, e-mail: Kosh.Pes@tatar.ru.

- Кощаково авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен проект экспозициясен китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Кощаково авыл җирлеге, Кощаково авылы, Комсомольская урамы, 13 йорт;

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә кисәтүнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып.

Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокуклы булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан булган урыннар турында белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга ризалыгын бирәләр.

Әлеге хәбәрне Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (http://pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, «Вперед» («Алга») газетасында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова